КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 март г.Казань № 229

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1078 нче, 2014 ел, 22 февраль, 109 нчы; 2014 ел, 24 февраль, 118 нче; 2014 ел, 30 апрель, 284 нче; 2014 ел, 2 июнь, 374 нче; 2014 ел, 17 июнь, 418 нче; 2014 ел, 8 июль, 473 нче; 2014 ел, 9 июль, 477 нче; 2014 ел, 25 август, 612 нче; 2014 ел, 1 октябрь, 709 нчы; 2014 ел, 24 ноябрь, 901 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 956 нчы; 2014 ел, 31 декабрь, 1083 нче; 2015 ел, 1 июнь, 390 нчы; 2015 ел, 24 июнь, 459 нчы; 2015 ел, 25 июнь, 460 нчы; 2015 ел, 28 июль, 549 нчы; 2015 ел, 16 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2015 ел, 28 декабрь, 992 нче; 2016 ел, 31 март, 190 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 268 нче; 2016 ел, 16 декабрь, 940 нчы; 2017 ел, 9 февраль, 73 нче; 2017 ел, 23 июнь, 423 нче; 2017 ел, 13 июль, 480 нче; 2017 ел, 21 октябрь, 802 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 1002 нче; 2018 ел, 27 июнь, 533 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1192 нче;

2019 ел, 11 февраль, 94 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 39 163 983,53 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 32 723 821,48 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 5 776 137,77 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган җирле бюджетлар акчасы исәбеннән –5 374,70 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 658 649,58 мең сум. |

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп ителергә планлаштырылган акча | | |
| | | | федераль бюджеттан | җирле бюджеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 3 669 180,12 | 1 794 954,55 | 1 717 775,57** | 100,0 | 156 350,0 |
| 2015 | 3 778 805,29 | 1 908 009,59 | 1 701 821,12*** | 150,0 | 168 824,58 |
| 2016 | 3 202 255,21 | 2 457 901,0 | 596 181,71**** | 472,5 | 147 700,0 |
| 2017 | 4 426 149,43 | 4 120 124,88 | 248 450,26* | 1 499,3 | 56 075,0 |
| 2018 | 5 522 954,95 | 5 419 467,55 | 71 405,8* | 906,6 | 31 175,0 |
| 2019 | 6 285 037,16 | 5 500 887,16 | 751 223,7* | 751,3 | 32 175,0 |
| 2020 | 6 098 978,46 | 5 628 011,06 | 437 044,9* | 747,5 | 33 175,0 |
| 2021 | 6 180 622,9 | 5 894 465,7 | 252 234,7* | 747,5 | 33 175,0 |
| Барлыгы | 39 163 983,53 | 32 723 821,48 | 5 776 137,77 | 5 374,7 | 658 649,58 |

Искәрмә: Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төгәенләнергә тиеш.

---

*Федераль бюджет акчасы исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнәчәк.

**Шул исәптән 193 209,83529 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган, 2014 елда үзләштерелгән акчасы.

***Шул исәптән 437 206,63906 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга

| | |
|---|---|
| | 2014 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган, 2015 елда үзләштерергә планлаштырылган акчасы.<br>****Шул исәптән 1 364,34855 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2015 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган, 2016 елда үзләштерергә планлаштырылган акчасы.<br>*****Шул исәптән 11 328,6 мең сум – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2017 елда алынып үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерергә планлаштырылган акча.<br>******Федераль бюджет исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнә»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 39 163 983,53 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 32 723 821,48 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 5 776 137,77 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган җирле бюджетлар акчасы исәбеннән –5 374,70 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 658 649,58 мең сум.

| Ел | Объем средств, тыс.рублей | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп ителергә планлаштырылган акча | | |
| | | | федераль бюджеттан | җирле бюд-жеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 3 669 180,12 | 1 794 954,55 | 1 717 775,57** | 100,0 | 156 350,0 |
| 2015 | 3 778 805,29 | 1 908 009,59 | 1 701 821,12*** | 150,0 | 168 824,58 |
| 2016 | 3 202 255,21 | 2 457 901,0 | 596 181,71**** | 472,5 | 147 700,0 |
| 2017 | 4 426 149,43 | 4 120 124,88 | 248 450,26* | 1 499,3 | 56 075,0 |
| 2018 | 5 522 954,95 | 5 419 467,55 | 71 405,8* | 906,6 | 31 175,0 |
| 2019 | 6 285 037,16 | 5 500 887,16 | 751 223,7* | 751,3 | 32 175,0 |
| 2020 | 6 098 978,46 | 5 628 011,06 | 437 044,9* | 747,5 | 33 175,0 |
| 2021 | 6 180 622,9 | 5 894 465,7 | 252 234,7* | 747,5 | 33 175,0 |
| Барлыгы | 39 163 983,53 | 32 723 821,48 | 5 776 137,77 | 5 374,7 | 658 649,58 |

Искәрмә: Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

______________

*Федераль бюджет акчасы исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия

Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнәчәк.

**Шул исәптән 193 209,83529 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган, 2014 елда үзләштерелгән акчасы.

***Шул исәптән 437 206,63906 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2014 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган, 2015 елда үзләштерергә планлаштырылган акчасы.

****Шул исәптән 1 364,34855 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2015 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган, 2016 елда үзләштерергә планлаштырылган акчасы.

***** Шул исәптән 11 328,6 мең сум – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2017 елда алынып үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерергә планлаштырылган акча.

******Федераль бюджет исәбеннән программаны ресурс белән тәэмин итү күләме федераль бюджеттан бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча ел саен билгеләнә.»;

Программага теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 – 2021 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="5">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td><td colspan="5">2015 – 2021 елларга Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 165 692,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 162 623,3 мең сум, һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 3 068,7 мең сум.</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="4">Акча күләме, мең сум</td></tr>
<tr><td>барлыгы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>федераль бюджеттан</td><td>бюджеттан тыш чыганаклардан</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>20 807,0</td><td>17 738,3</td><td>-</td><td>3 068,7</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>14 500,0</td><td>14 500,0</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2017 | 9 957,5 | 9 957,5 | - | - |
| | 2018 | 9 957,5 | 9 957,5 | - | - |
| | 2019 | 36 660,0 | 36 660,0 | * | - |
| | 2020 | 36 760,0 | 36 760,0 | * | - |
| | 2021 | 37 050,0 | 37 050,0 | * | - |
| | Барлыгы | 165 692,0 | 162 623,3 | * | 3 068,7 |
| | * Федераль бюджет акчасы исәбеннән ресурслар белән тәэмин итү күләме «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Россия Федерациясе субъектларын грант ярдәме күрсәтү системасы аша хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру эшләрен тормышка ашыруга стимуллаштыру» чарасы кысаларында конкурс нигезендә билгеләнәчәк; | | | | |

Ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру тармаклары тасвирламасы, хәл итү өчен Ярдәмче программа юнәлдерелгән проблемалар, аларны чишү юллары

Татарстан Республикасы алдында торган төп бурыч – икътисад тармакларының көндәшлек сәләтен тәэмин итү. Россия, Беларусия һәм Казахстанның Таможня берлеген оештыруга һәм Россия Федерациясенең Бөтендөнья сәүдә оешмасына әгъза булып керүенә бәйле рәвештә, соңгы елларда бу мәсьәләнең актуальлеге артты. Россиянең халыкара сәүдәгә тирәнрәк интеграцияләнәве бизнес өчен тагын да катгыйрак көндәшлек мохитен булдыруга этәрә, бу предприятиеләрнең нәтиҗәлелеген арттыру юлларын эзләргә мәҗбүр итә.

Хезмәт җитештерүчәнлеге икътисадның көндәшлек сәләтенең төп факторы һәм икътисадый үсеш өчен нигез булып тора. Җитештерүчәнлек факторының йогынты ясавы макроикътисадый дәрәҗәдә дә, шулай ук аерым предприятиеләр дәрәҗәсендә дә бер үк әһәмияткә ия.

Макроикътисадый яктан караганда җитештерүчәнлек республиканың иминлеген яхшыртуда төп факторларның берсе булып тора. Шул ук вакытта нәкъ менә тагы да нәтиҗәлерәк итеп товарлар җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеге өстәмә кыйммәтнең, ягъни тулаем төбәк продуктының (алга таба – ТТП) тулаем артуын гына түгел, ә аның сыйфатлы артуын да тәэмин итә. Нәтиҗәле производство җитештерелә торган товарларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләмен һәм сыйфатын арттырырга һәм, ахыр чиктә, халыкның тормыш сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә.

Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру бурычы Россия Федерациясе Президентының «Озак вакытлы дәүләт икътисадый сәясәте турында» 2012 ел, 7 май, 596 нчы; «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм

максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 ел, 7 май, 204 нче указларында өстенлекле юнәлешләрнең берсе буларак билгеләнде.

Аерым предприятие дәрәҗәсендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру бизнесның көндәшлек сәләтен тәэмин итәргә (чыгымнарны киметергә, инвестиция капиталын тупларга, акционерлар, хезмәткәрләр һәм дәүләт алдындагы үз бурычларны үтәргә) мөмкинлек бирәчәк.

Гомумән алганда җитештерүчәнлек – ул продукция чыгару күләмнәренең аны чыгару өчен сарыф ителгән, бердәй үлчәү берәмлекләрендә чагылдырылган ресурслар күләмнәренә чагыштырмасы дип аңлашыла, ягъни продукциянең бер берәмлеген җитештерү өчен сарыф ителгән ресурс чыгымнарына бәя бирелә. Җитештерүчәнлеккә җентекле анализ ясау катлаулырак формула буенча гамәлгә ашырыла, әмма җитештерүчәнлек төшенчәсенең төп концепциясе үзгәрешсез кала – сарыф ителгән ресурсларның 1 берәмлегенә продукция җитештерү. Продукция җитештерү дигәндә хисап чорында хуҗалык итүче берәмлекнең яки тулаем илкүләм икътисадның җитештерү эшчәнлеге нәтиҗәсе булган товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми кыйммәте дип аңлатыла. Ресурслар чыгымнары – ул җитештерүнең барлык факторлары (хезмәтне, капиталны, җирне һәм җитештерү процессына җәлеп ителгән башка факторларны да кертеп) дигәнне аңлата. Җитештерүчәнлек аерым предприятиеләр, кластерлар, төбәкләр һәм тармаклар яки тулаем барлык икътисад дәрәҗәсендә бәяләнергә мөмкин. Җитештерүчәнлек аерым җитештерү факторының бер берәмлегенә (мәсәлән, яллы хезмәт) яки авыл хуҗалыгында җирнең бер берәмлегенә исәпләнергә яки аны җитештерү факторларының төрле төрләрен агрегацияләүне күздә тота торган җыелма җитештерүчәнлек белән чагыштырылырга мөмкин.

Җитештерүчәнлек үсеше – ул җитештерү факторларын, ягъни сарыф ителә торган ресурсларны файдалану нәтиҗәлелеге арту дигәнне аңлата. Җитештерүчәнлек үсеше ресурсларның продукция берәмлеген җитештерү чыгымнарын киметүне тәэмин итә, бу исә гамәлдә түбәндәгеләрдә чагылыш таба:

җитештерү күләмнәрен саклаганда яки арттырганда ресурсларның чыгымнарын чагыштырмача киметүдә;

сарыф ителә торган ресурслар күләмен саклаганда яки киметкәндә җитештерү күләмнәрен чагыштырмача арттыруда.

Шулай итеп, югары хезмәт җитештерүчәнлеге ресурслардан нәтиҗәлерәк файдалануга туры килә. Мәсәлән, эш белән тәэмин ителгән бер кеше өчен җитештерүчәнлек хезмәт интенсивлыгын арттыру, эшче көчләр ягыннан осталыкны арттыру хисабына яки капиталь җиһаз, камилләштерелгән технология һәм иң яхшы идарә итү исәбенә үсә ала. Җитештерүчәнлекнең үсеше ил, төбәк, кластер, предприятие, цех, участок дәрәҗәсендә тәэмин ителергә мөмкин.

Җитештерүчәнлек ил, төбәк, кластер яки аерым предприятие икътисадының көндәшлек сәләтен тәэмин итә, булдырылган өстәмә кыйммәткә һәм халыкның иминлегенә йогынты ясый.

Җитештерүнең гомуми күләме җыелма өстәмә кыйммәткә туры килгәнгә күрә, гомуми җитештерүне арттыру тулаем төбәк продуктының үсешенә туры килә. Шул итеп, җитештерүчәнлекнең үсеше икътисадның иминлеге көчәюгә турыдан-туры йогынты ясый.

Җитештерүчәнлек үсеше һәм халыкның керемнәре үсеше арасындагы элемтәне җан башына тулаем төбәк продуктының фундаменталь күрсәткече аша күрсәтергә мөмкин, ул гомуми җитештерүнең (җыелма өстәмә кыйммәтнең) халык санына карата исәпләнә һәм кешеләрнең иминлеген һәм тормыш стандартларын үлчәү өчен кулланыла.

Үз чиратында, гомуми тулаем төбәк продуктын хезмәт җитештерүчәнлегенең һәм хезмәт чыгымнарының тапкырчыгышы итеп күзалларга мөмкин. Димәк, җан башына тулаем төбәк продукты, ягъни халыкның иминлеге күрсәткече турыдан-туры икътисадтагы хезмәт җитештерүчәнлеге күрсәткеченә бәйле була.

Еллык эш хакы югары булган илләр югары хезмәт җитештерүчәнлеге белән аерылып тора, үз чиратында, хезмәт җитештерүчәнлеге түбән булган илләргә еллык керемнәрнең түбән дәрәҗәдә булуы хас. Эш хакының һәм хезмәт җитештерүчәнлегенең югары күрсәткечләрен үз эченә алган аеруча үсеш алган илләр җитештерүдә өстәмә кыйммәте югары булган дифференцияләнә торган продукциягә юнәлдерелгән дөньякүләм технологик алдынгы илләр булып торалар. Шулай итеп, хезмәт җитештерүчәнлеге – ул халык муллыгын һәм икътисад иминлеген арттыруның төп факторы булып тора, чөнки икътисадта югары хезмәт җитештерүчәнлеге зуррак өстәмә кыйммәт булдырырга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта хезмәткәрләрнең муллык дәрәҗәсен арттыруны барлыкка китерә торган җитештерүчәнлекне арттыруга стимуллар белән кире бәйлелек дә бар.

Аерым компанияләр дәрәҗәсендә җитештерүчәнлекнең үсеше түбәндәгеләргә этәрә:

хезмәткәрләр өчен хезмәт өчен түләүне һәм аның шартларын яхшыртуны арттыруга;

акционерлар өчен компанияләр кыйммәте артуга;

кулланучылар өчен товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләр төшүгә;

дәүләт файдасына салым түләүләрне арттыруга.

Җитештерүчәнлекнең үсеше компания өчен мөһим була, чөнки ул бизнеска үз хезмәткәрләре, акционерлары һәм дәүләт алдындагы бурычларын үтәргә һәм шул ук вакытта базарда көндәшлек позициясен сакларга һәм көчәйтергә мөмкинлек бирә. Гомуми җитештерүне, ягъни җитештерелә торган тулаем өстәмә кыйммәтне арттыруның ике ысулы бар: ресурсларны куллануны арттыру яки җитештерүчәнлекнең үсешен тәэмин итү. Әмма файдаланыла торган ресурсларның күләмен арттыру кулланыла торган ресурслар берәмлегенә керемнәр үсешен тәэмин итми (әгәр дә масштабның шактый зур даими уңай нәтиҗәсе булмаса). Практикада бу еш кына эш хакының кимүенә һәм бизнесның рентабельлелегенең төшүенә китерә. Үз чиратында, хезмәт җитештерүчәнлегенең ресурсларны куллануны арттырмыйча да үсеше булдырыла торган өстәмә кыйммәтне арттыруга китерә, ә сарыф ителә торган ресурсларның бер берәмлегеннән алына торган керем арта.

Хезмәт җитештерүчәнлеге үсешенең мөһим үзенчәлеге: эшсезлек дәрәҗәсенең системалы рәвештә күтәрелүен булдырмау булып тора.

Аерым компания җитештерүчәнлеге үсеше (мәсәлән, җитештерүнең яңа, тагы да нәтиҗәлерәк технологиясен кулланышка кертү ярдәмендә ирешергә мөмкин була торган) кыска вакытлы чорга эш белән тәэмин итүне аз гына киметергә мөмкин. Әмма инновацияле технологияләрне актив кулланышка кертүче һәм инновацияле

продуктларны актив җитештерүче компанияләр, кагыйдә буларак, җитештерүгә технологияләрне яки продуктны уңышлы кулланышка керткәннән соң, базарның күп өлешен контрольдә тоту өчен үз хезмәткәрләренең санын торгызырга яки арттырырга омтыла. Шул ук вакытта яңа технологияләрне кулланышка кертү югарырак квалификацияле эшче көчкә ихтыяҗны арттыра, бу эш хакы дәрәҗәсендә дә, компаниянең үз персоналын әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү чыгымнарында да уңай чагылыш таба. Моннан тыш, уртача һәм озак вакытка исәпләнгән чорда кайбер предприятиеләрдә нәтиҗәсез файдаланыла торган хезмәт ресурсларын бетерү икътисадта предприятиеләр арасындагы хезмәтне яңадан бүлүгә китерә.

Татарстан Республикасы предприятиеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү өчен зур потенциалга ия. Тулаем алганда, Татарстан Республикасында җитештерүчәнлек күрсәткече Икътисадый хезмәттәшлек һәм үсеш оешмасы илләренә хас булган шундый ук уртача күрсәткечтән 1,5 тапкырга түбәнрәк.

Соңгы 5 елда Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеге чынбарлыкта 16 процентка, ә реаль эш хакы 25 процентка артты. Әгәр дә республика буенча уртача бер хезмәткәр җитештергән өстәмә кыйммәтнең һәр сумыннан якынча 25 тиене аңа эш хакын түләү өчен җибәрелсә, кайбер предприятиеләрдә бу нисбәт 50 проценттан артып китә. Предприятиеләрне алга таба үстерү һәм эш хакын күтәрү өчен бердәнбер резерв булып хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү тора. Предприятиеләрдә бер эшчәнлек төре кысаларында хезмәт җитештерүчәнлеге дәрәҗәсе шактый аерылып торырга мөмкин, бу җитештерүчәнлекне арттыру өчен резервлар барлыгын күрсәтә. Резервлардан нәтиҗәле файдалану тиешле дәрәҗәдә булмау турында югары җитештерүчәнлекле эш урыннары санының динамикасы дә сөйли. Югары җитештерүчәнлекле эш урыннарына хезмәткәрләрнең уртача айлык эш хакы (шәхси эшмәкәрләр өчен – уртача керем) критерийларның билгеләнгән күләменә (иң чик мәгънәсе)[1] тигез булган яки аннан артып киткән предприятиеләрнең (оешмаларның) барлык биләнгән урыннары керә. Татарстан Республикасы алдында 2021 елга 750 мең югары җитештерүчәнлекле эш урынын булдыру һәм модернизацияләү бурычы тора. 2013 ел йомгаклары буенча аларның саны 489,7 мең, 2012 ел белән чагыштырганда үсеш 9 процент тәшкил итте. Шул ук вакытта сәнәгатьтә югары җитештерүчәнлекле эш урыннары үсеше бары тик 6,2 процент кына тәшкил итте.

Хезмәт җитештерүчәнлеген тоткарлый торган факторлар:

Җитештерүчәнлек дәрәҗәсен билгели торган факторлар җыелмасы ике төркемгә: тышкы һәм эчке факторларга бүленә:

1. Тышкы факторларга түбәндәгеләр керә:

базардан файдалана алу мөмкинлеге һәм көндәшлек;

инфраструктура;

финанс ресурслары;

кеше ресурслары һәм күнекмәләр;

---

[1] «Югары җитештерүчәнлекле эш урыннары үсеше, узган елга карата процентларда» күрсәткечен исәпләү методикасы (Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең 2017 ел, 9 октябрь, 665 нче боерыгы белән расланды)

тәэмин итүчеләрнең экосистемасы;

административ җайга салу.

2. Эчке факторларга түбәндәгеләр керә:

җиһаз һәм активлар;

азык-төлек портфеле;

маркетинг һәм сату;

менеджмент һәм процесслар;

чимал һәм материаллар;

кадрлар.

Эчке һәм тышкы факторлар арасында принципиаль аерма: эчке факторлар, күпчелек очракта, компанияләрнең үзләренең эшчәнлегенә бәйле була. Шуңа күрә тиешле ярдәм күрсәтелгәндә һәм институциональ яктан тәэмин ителгәндә, предприятиеләр үзләре дә чараларның киң җыелмасы ярдәмендә эчке факторларны үстерүгә йогынты ясый ала, бу ахыр чиктә хезмәт җитештерүчәнлеге үсешенә китерергә мөмкин. Бу очракта җитештерүчәнлекне үстерү проблемаларын хәл итүгә игътибарны юнәлдерү максаты белән шәхси компанияләргә дә, дәүләт катнашындагы оешмаларга да стимул бирә һәм ярдәм күрсәтә торган йогынты ясарга тиеш. Тышкы факторлар, үз чиратында, компанияләр йогынтысыннан читтә урнашканнар. Аларның үсешендә төп рольне төбәк һәм федераль хакимият органнары уйнарга тиеш. Бу өлештә җитештерүчәнлекне үстерүне тәэмин итү программасының уңышы тулысынча дәүләт секторы тарафыннан күрелә торган адымнарның төптән уйланылуына һәм сыйфатына бәйле була.

Системалы дәрәҗәдә, озак вакытка исәпләнгән чорда һәм даими нигездә җитештерүчәнлекнең үсешен тәэмин итү өчен конкрет мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән ярдәм күрсәтү чараларының комплекслы системасын кулланырга кирәк. Ресурсларның кирәкле күләмен җәлеп итәргә һәм күп кенә субъектларны яраштырырга бары программа-максатчан алымны кулланып һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең актив роль уйнавыннан файдаланып кына була.

Татарстан Республикасының барлык сәнәгать җитештерүе күләменең якынча 60 процентын тәэмин итүче нефть химиясе һәм машина төзелеше предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген һәм югары җитештерүчәнлекле эш урыннары санын арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 февраль, 99 нчы карары белән Россиядә беренче «2013 – 2016 елларга Татарстан Республикасының машина төзелеше һәм нефть химиясе комплекслары предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» озак вакытлы максатчан программасы расланды.

Әлеге программаның операторы сыйфатында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Энергияне саклаучы технологияләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе билгеләнде, аңа хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча пилот проектларын тормышка ашыру өчен консалтинг оешмасы һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның республика үзәге функцияләре йөкләнде.

2013 елда хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча озак вакытлы максатчан программа чараларын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасының Энергия саклаучы технологияләр үзәге тарафыннан предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү резервларына финанс-икътисадый һәм технологик аудит

үткәрү методикасы эшләнде. Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча пилот проектларын тормышка ашыру предприятиеләре буларак «Алнас» ачык акционерлар җәмгыяте (машина төзелеше комплексы) һәм «Л.Я.Карпов исемендәге Химия заводы» ачык акционерлар җәмгыяте (нефть химиясе комплексы) билгеләнде.

Әлеге предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү резервларына финанс-икътисадый һәм технологик аудит үткәрелде, аның нәтиҗәләре буенча 2013 – 2016 елларга хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча пилот проектлары эшләнде.

«Алнас» ачык акционерлар җәмгыятендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруны тәэмин итә торган комплекслы проект түбәндәге юнәлешләрне үз эченә ала:

технологик нәтиҗәлелекне камилләштерү буенча чараларны кулланышка кертү (технологик модернизацияләү, энергия хуҗалыгын модернизацияләү);

персонал санын оптимальләштерү;

җитештерү белән идарә итү системасын камилләштерү буенча чараларны кулланышка кертү;

персоналны әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү.

«Л.Я.Карпов исемендәге Химия заводы» ачык акционерлар җәмгыятендә үткәрелгән аудит нәтиҗәләре буенча технологик нәтиҗәлелекне күтәрү, профильле булмаган җитештерүләрне аутсорсингка чыгарып, предприятиене реструктурлаштыру буенча проектлар булдырылды, аларны 2 төркемгә бүләргә мөмкин:

предприятиенең оештыру һәм идарә итү структурасын оптимальләштерү буенча проектлар;

җитештерү процессларын оптимальләштерү буенча проектлар.

Республиканың сәнәгать предприятиеләре өчен гамәли ярдәм күрсәтү сыйфатында предприятиедә җитештерүчәнлекне арттыру буенча программалар эшләүнең бертип тәкъдимнәр әзерләнде, аларда компанияләрнең хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча кирәкле гамәлләр спектры билгеләнде.

Татарстан Республикасының нефть химиясе һәм машина төзелеше комплексы предприятиеләре өчен хезмәт җитештерүчәнлеген һәм операцион нәтиҗәлелекне арттыру мәсьәләләре буенча 2 семинар оештырылды.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталында (www.ppt.tatarstan.ru) хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру мәсьәләләре буенча интернет-сайт һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Энергия саклаучы технологияләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе сайтында (www.cet.tatarstan.ru) хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча интернет-бит булдырылды.

Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру юнәлешләренең берсе – ул сакчыл җитештерү принципларын һәм инструментларын кулланышка кертү.

Татарстан Республикасының предприятиеләрнең җитештерү процессына «Сакчыл җитештерү» методикасын кулланышка кертү буенча уңышлы тәҗрибәсе бар.

2012 елда республикада «2013 – 2016 елларга Татарстан Республикасының машина төзелеше һәм нефть химиясе комплекслары предприятиеләрендә хезмәт

җитештерүчәнлеген арттыру» озак вакытлы максатчан программасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 февраль, 99 нчы карары белән расланды) Россиядә беренче кабул ителде. Программа предприятиеләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген, беренче чиратта, катлаулы фәнни нигезләүне таләп итә торган машина төзелешен җитештерүне оптимизацияләү һәм заманча технологияләрне кертү хисабына этаплап арттыруга юнәлдерелә. Программаның максаты – хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү, предприятиеләрнең рентабельлелеген арттыру, республика икътисадының төрле тармаклары өчен сакчыл җитештерү мәсьәләләре буенча кадрларны һөнәри әзерләү.

Сакчыл җитештерү технологияләрен кулланышка кертү нәтиҗәләре аларны берничә ел эчендә системалы куллана торган республика предприятиеләрендә аеруча сизелә. Аларны куллану нәтиҗәләре аеруча «КАМАЗ» ачык акционерлар җәмгыятендә күренә. Аларны кулланышка кертүдән икътисадый нәтиҗә 27 млрд. сумнан артыграк тәшкил итте. Предприятиедә сакчыл җитештерү технологияләрен кулланышка кертү буенча масштаблы проектларның берсе «Маяк» проекты булды. 2011 елда тормышка ашырылган проектның максаты – «КАМАЗ» ачык акционерлар җәмгыятенең автомобиль заводының техпроцессларын оптимальләштерү. Немец партнеры – Daimler компаниясенең операция системасының заманча стандартларын кулланышка кертү ярдәмендә куелган бурычка ирешелде. Проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә автомобиль заводында хезмәт җитештерүчәнлеге 49 процентка артты.

Тулаем алганда, сакчыл җитештерү принципларын һәм инструментларын кулланышка кертүче предприятиеләр минималь кертемнәр белән түбәндәге нәтиҗәләргә ирешә: хезмәт җитештерүчәнлеге арту – 70 процентка кадәр, җитештерелә торган продукциянең сыйфаты яхшыру – 60 процентка кадәр, җитештерү мәйданнарыннан азат булу – 50 процентка кадәр, бракны киметү – уртача 65 процентка кадәр, инвестиция проектларын тормышка ашыру вакытларын кыскарту – 20 процентка кадәр. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: сакчыл җитештерү принципларын һәм инструментларын кулланышка кертү нәтиҗәсендә предприятиедәге эшчеләрнең, инженер-техник кадрларның һәм җитәкчеләрнең психологиясе, менталитеты үзгәрә.

2014 елның 1 гыйнварыннан дәүләт программалары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыруга күчү гамәлгә ашырылды, шуңа бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары озак вакытлы максатчан программаларны гамәлгә ашырырга хокуксыз. Әлеге вакыттан соңрак төгәлләүне күздә тоткан, хәзерге вакытта озак вакытлы максатчан программаларга кертелгән чараларны тормышка ашыруны дәвам итү Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программалары кысаларында мөмкин.

Шуңа бәйле рәвештә республика предприятиеләрендә җитештерүчәнлекне арттыру буенча системалы эшләүнең нигезен формалаштыру максаты белән «2013 – 2016 елларга Татарстан Республикасы машина төзелеше һәм нефть химиясе комплекслары предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» озак вакытлы максатчан программасының сакчыл җитештерү проекты чаралары белән тулыландырылган төп чаралары «Татарстан Республикасы предприятиеләрендә

хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы сыйфатында «2014 – 2021 елларга икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Татарстан Республикасы дәүләт программасына кертелде.

2017 елда, Татарстан тәҗрибәсен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» өстенлекле проекты эшләнде (Россия Федерациясе Президенты каршындагы Стратегик үсеш һәм өстенлекле проектлар буенча совет президиумының 2017 ел, 30 август, 9 нчы беркетмәсе белән расланды). Татарстан Республикасы әлеге проектны тормышка ашыру буенча пилот төбәкләре арасына керде. 2017 – 2018 елларда проектта сәнәгатьнең эшкәртү тармакларына караган 19 предприятие катнашты.

2018 елда Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 ел, 7 май, 204 нче Указы нигезендә «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» өстенлекле проекты эшләп бетерелде һәм «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты (алга таба – Илкүләм проект) рәвешендә тәкъдим ителде.

Икътисадның чимал булмаган төп тармакларының урта һәм эре предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеге үсешен 1 елга 5 процентган түбәнрәк тәэмин итү һәм Илкүләм проект чараларын тормышка ашыру өчен 10 мең предприятие җәлеп итү Илкүләм проектның максатлары итеп билгеләнде.

Илкүләм проектны тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә кирәк:

Татарстан Республикасы икътисадының чимал булмаган база тармакларына (сәнәгать, авыл хуҗалыгы, транспорт, төзелеш) караган 246 предприятиенең Илкүләм проекты чараларын тормышка ашыруда катнашу;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының һәм «Хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендәге компетенцияләрнең федераль үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешма методологиясе буенча җитештерүне үстерүгә, чыгымнарны киметүгә юнәлдерелгән хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча пилот проектларын тормышка ашыру;

идарә итүнең инновацион инструментларын кулланышка кертү;

предприятие персоналын укыту, предприятиеләр җитәкчеләре һәм белгечләренең квалификациясен күтәрү.

Хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендәге компетенцияләрнең төбәк үзәге итеп «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Энергия саклаучы технологияләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе билгеләнде.»;

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, төп чараларының тасвирламасы, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Ярдәмче программаның максаты – Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген һәм югары җитештерүчәнлекле эш урыннары санын арттыру.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру йомгаклары буенча Ярдәмче программада катнашучы предприятиеләрдә ел саен хезмәт җитештерүчәнлеген 5 процентка арттыру тәэмин ителгән.

Бу максатка ирешү өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасының башка министрлыклары, ведомстволары һәм оешмалары тарафыннан түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Татарстан Республикасы предприятиеләрен хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга юнәлдерелгән нәтиҗәле үзгәртеп коруларны үткәрүгә стимуллаштыру.

2. Татарстан Республикасы предприятиеләренең хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү һәм арттыру өчен агымдагы (инфраструктура, ресурс (шул исәптән кадрлар) һәм административ) чикләүләрне бетерү һәм уңайлы тышкы шартлар тудыру.

3. «Сакчыл җитештерү» методикасы принципларын һәм инструментларын файдаланып, Татарстан Республикасы предприятиеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.

Республика предприятиеләрен хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга юнәлдерелгән нәтиҗәле үзгәртеп коруларны үткәрүгә стимуллаштыру максатларында түбәндәгеләр планлаштырыла:

Ярдәмче программада катнашучы предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру мәсьәләләре буенча, шул исәптән оештыру ягыннан үзгәрешләр кертү һәм процесс белән идарә итү инструментларын кулланышка кертү буенча эшче төркемнәр төзү һәм аларның эшчәнлегенә методик ярдәм күрсәтү;

төзелгән эшче төркемнәр тарафыннан хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү резервлары аудитын үткәрү;

Ярдәмче программада катнашучы предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру проектларын һәм программаларын эшләү.

Татарстан Республикасы предприятиеләренең хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү һәм арттыру өчен агымдагы (инфраструктура, ресурс (шул исәптән кадрлар) һәм административ) чикләүләрне бетерү һәм уңайлы тышкы шартлар тудыру бурычын тормышка ашыру кысаларында түбәндәге чаралар күздә тотыла:

хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру мәсьәләләре, «Сакчыл җитештерү» методикасын кулланышка кертү, проектларны тормышка ашыруга дәүләт ярдәме күрсәтү проблемалары буенча Татарстан Республикасы предприятиеләре җитәкчеләре һәм белгечләре өчен семинарлар, киңәшмәләр, «түгәрәк өстәлләр» үткәрү;

хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча консультация һәм мәгълүмати-консалтинг хезмәтләре күрсәтү;

республика предприятиеләре өчен хезмәт җитештерүчәнлеге мәсьәләләре буенча интернет-сайтны (http://ppt.tatarstan.ru/) алып бару;

сәнәгатьтә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру проектларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен һәм алдынгы тәҗрибәне анализлау, нәтиҗәләрне интернет-сайтта (http://ppt.tatarstan.ru/) урнаштыру;

хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати-аналитик материал әзерләү һәм бастырып чыгару;

предприятиеләргә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру проектларына субсидия бирүнең һәм дәүләт ярдәме күрсәтүнең гамәлдәге чаралары турында мәгълүмат бирү.

Ярдәмче программа кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, республика предприятиеләрен «Сакчыл җитештерү» технологияләрен җитештерү эшчәнлегенә кулланышка кертүгә стимуллаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру күздә тотыла:

«Сакчыл җитештерү» методикасын эшләү һәм кулланышка кертү мәсьәләләре буенча республика предприятиеләре һәм оешмалары персоналының гамәли тренингларын оештыру һәм үткәрү;

сакчыл җитештерү инструментларын кулланып, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча пилот проектын кулланышка кертү буенча Ярдәмче программада катнашучы предприятиеләрдә эшче төркемнәргә комплекслы методик һәм консультация ярдәме күрсәтү;

төп продуктларның үрнәкләрен – агымнарын булдыруга юнәлдерелгән, сакчыл җитештерү инструментларын кулланып, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча пилот проектларын башкару, алга таба алынган нәтиҗәләрне тиражлау;

сакчыл җитештерү инструментларын кулланып, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча пилот проектларын тормышка ашыручы Ярдәмче программада катнашучы предприятиеләрдә эшче төркемнәр төзү;

сакчыл җитештерү инструментларын кулланып, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру мәсьәләләре буенча Ярдәмче программада катнашучы предприятиеләр хезмәткәрләрен укыту.

Югарыда күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча реаль проектларны эшләүнең һәм тормышка ашыруның берничә уңай үрнәкләрен булдырырга мөмкинлек бирәчәк. Алга таба пилот предприятиеләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 6 февраль, 85 нче карары белән расланган «2012 – 2013 елларга Татарстан Республикасында «Сакчыл җитештерү» методикасын тормышка ашыру» озак вакытлы максатчан программасын тормышка ашыру буенча республикадагы тәҗрибә охшаш булган хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру инструментларын

гамәли кулланышка кертү буенча өчен семинарлар үткәрү өчен мәйданчыклар сыйфатында кулланылачак.

Тулаем алганда, бу республика предприятиеләренең җитештерүчәнлеген һәм көндәшлек сәләтен арттыру идеологиясен популярлаштыруга, предприятиеләрнең әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә активлыгын һәм инициативалылыгын үстерүгә ярдәм итәргә тиеш.

Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру бу юнәлештәге максатларга һәм бурычларга ирешүгә генә түгел, тулаем алганда, предприятиеләрдә җитештерүчәнлекне үстерүгә карата тышкы һәм эчке киртәләрне бетерү хисабына Татарстан Республикасы икътисади үсешенә дә ярдәм итәчәк, предприятиеләргә базарда көндәшлеккә сәләтлерәк булырга мөмкинлек бирәчәк һәм хезмәт шартлары яхшыру һәм эш хакы арту өлешендә социаль эффект алырга мөмкинлек бирәчәк.

Чыгымнарны киметүгә, җитештерүне үстерүгә, югары җитештерүчәнлекле эш урыннары булдыруга юнәлдерелгән хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча пилот проектлары Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм «Хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендә федераль компетенцияләр үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы методологиясе буенча тормышка ашырыла.

Максатлар, бурычлар, чаралар яктылыгында Ярдәмче программа нәтиҗәләрен бәяләүнең максатчан индикаторлары Ярдәмче программага теркәлгән кушымтада бирелә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты: 2015 – 2021 еллар.»;

Ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителеше

<table>
<tr><td rowspan="7">Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td><td colspan="5">2015 – 2021 елларга Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 165 692,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 162 623,3 мең сум, һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 3 068,7 мең сум.</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="4">Акча күләме, мең сум</td></tr>
<tr><td>барлыгы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>федераль бюджеттан</td><td>бюджеттан тыш чыганаклардан</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>20 807,0</td><td>17 738,3</td><td>-</td><td>3 068,7</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>14 500,0</td><td>14 500,0</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>9 957,5</td><td>9 957,5</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>9 957,5</td><td>9 957,5</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2019 | 36 660,0 | 36 660,0 | * | - |
| | 2020 | 36 760,0 | 36 760,0 | * | - |
| | 2021 | 37 050,0 | 37 050,0 | * | - |
| | Барлыгы | 165 692,0 | 162 623,3 | * | 3 068,7 |
| | * Федераль бюджет акчасы исәбеннән ресурслар белән тәэмин итү күләме «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Россия Федерациясе субъектларын грант ярдәме күрсәтү системасы аша хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру эшләрен тормышка ашыруга стимуллаштыру» чарасы кысаларында конкурс нигезендә билгеләнәчәк; | | | | |

Ярдәмче программаның V бүлегендәге «Ярдәмче программаны тормышка ашыруны бәяләү индикаторлары» таблицасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Икътисадның чимал булмаган база тармакларына караган һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру чараларын тормышка ашыруга җәлеп ителгән предприятиеләр саны, арта бара торган йомгак белән берәмлек | - | - | - | - | 15 | 63 | 89 | 130»; |

Ярдәмче программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин